**Тема:** Нәрсә ул батырлык?

**Максат**:

1. Батырлык төшенчәсен аңлату, батырлыкны дәлилли белүләренә ирешү. Сугышның кырыс чынбарлыгын, халкыбызның сугыш кырларындагы батырлыгын, патриотизмын һәм милли горурлыгын күрсәтү.
2. Укучыларны мөстәкыйль фикер йөртүгә өйрәтү аша, сугыш ветераннарына хөрмәт – ихтирам хисләре, кешелеклелек сыйфатлары, җаваплылык хисе тәрбияләү.
3. Сөйләм әдәбен камилләштерү буенча эшләү. Сәламәт, тыныч яшәүнең әһәмиятенә игътибарны арттыру.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Балаларның батырлык сыйфатын үзләрендә тәрбияләү теләген уятырга.
- Батырлыкның төп билгеләрен аңлау.
- Батырлык кешеләрне көрәшеп егуда түгел, бәлки ачу вакытында үзен тота белүдә икәнен белү.

**Эпиграф:**

- *Батырлык кешеләрне көрәшеп егуда түгел, бәлки ачу вакытында үзен тота белүдә. /Хәдис/*
- *“Батырлык көндәлек очрап торган авырлыкларга үҗәтләнеп каршы барганда тәрбияләнә.”* /Н.Островский/

**Дәрес барышы.**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

**-** Шигъри юлларны тыңлап, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

Батырлык. Бу купшы сүз түгел,
Хәтерләрдән тиз җуела торган.
Мәгънә - асылында, мәңгелеккә
Күңелләргә, җанга уела торган.
Кайсы тауның ташларыннан икән
Батырлыкка һәйкәл куясы?
Чорлар җиле ташларны да уя,
Тик мәңгелек хәтер кыясы!
Батырлык дип күпме сөйләп йөрмик,
Күпме аны күккә күтәрмик,
Ише бармы бөеклекнең солдат
Кылган батырлыкка тиңләрлек?

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүгенге дәреснең темасы ... (Батырлык).

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

- Хөрмәтле укучылар! Безнең бүгенге дәресебез нәкъ менә шундыйлар хакында, мин сезне бүген батырлык темасына сөйләшүгә чакырам.

**1. Төшенчә биру. Нәрсә ул батырлык?**

- Батырлык ул кешеләрне бик авыр очракларда коткару. Сугыш вакытында да кешеләр бик күп батырлыклар эшләгәннәр. (Укучылар җавабын тыңлау).

**- Ә хәзер аңлатмалы сүзлектән уку.**

*Батырлык* 1) Батыр булу сыйфаты, курыкмаучанлык, кыюлык.
2) Батырчылык, тәвәккәллек. (134 б., I том.)

- Чыннан да, бу сыйфатлар бик уңай сыйфатлар. Тәвәккәл сүзенә аңлатма да биреп китим әле. **Тәвәккәл** – 1) берәр эшкә кыю керешүче, аны икеләнүсез үтәүче. 2) үз – үзеңә ышанучанлык.

Нәрсә соң ул батырлык? Аның төп мәгънәсен һәркем үзенең тормышка карашларыннан чыгып, үзенчә аңлый. Ә шулай да, батырлык ул, мөгаен, гадәти күзлектән караганда һич кенә дә кеше башкара алмастай эшне башкарудыр. Ул кешедән чиксез ихтыяр көче, тәвәккәллек, үз-үзеңне аямауны таләп итә.

**-** Батырлык эшләү өчен нинди сыйфатлар кирәк? (кыю, көчле, тәвәккәл, акыллы, тырыш, зиһенле, игътибарлы, җитез*).*

**2. Бөек Ватан сугышы елларындагы батырлары**.

- Бөек Ватан сугышы елларындагы батырларны беләсезме?

- Исемнәрен атагыз. Алар нинди батырлыклары белән танылганнар? (Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин, Бари Шәвәлиев, Муса Җәлил, Мәгубә Сыртланова, Фатих Кәрим һ. б.)

*Александр Матросов 1943 елның 27 февралендә 2-нче батальонга Псков өлкәсенең Локнян районы Чернушки авылындагы терәк пунктка һөҗүм итәргә дигән бурыч йөкләнә. Солдатлар урман аша үтеп аланга чыгуга, дошманның пулемет уты астына эләгәләр. Беренче пулеметны автоматчылар төркеме эштән чыгара, икенчесен дә туктатуга ирешәләр. Әмма өченче дзоттан атучы пулемет авылга керергә мөмкинлек бирми.*

*Шул вакыт Александр Матросов Петр Огурцов белән дзотка таба шуыша башлыйлар. Дзотка якынлашканда, Огурцов каты яралана, Матросов юлын үзе генә дәвам итә. Ул амбразурага якынрак килеп ике граната ыргыта. Пулемет тынып кала. Дошманнар һөҗүмгә ташлануга, ул тагын ут ача. Шулчак Матросов сикереп торып дзотка ыргыла һәм амбразураны каплый. Шулай итеп, ул үзен корбан итеп хәрби бурычын үти. 1943 елның 19 июнендә аңа Советлар берлеге каһарманы дигән исем бирелә.*

*Матросов батырлыгы дәреслекләргә совет ватанына мәхәббәт, куркусызлык, каһарманлык билгесе булып кереп кала. Дөреслектә, Александр Матросов-Шакирҗан Мөхәммәтҗанов татар егете икәне исбатлана. Бу турында 2008 елда Мәскәүдә документаль фильм төшерелә. Анда Матросовның Шакирҗан Мөхәммәтҗанов булуы әйтелә.*

- Әлбәттә, сугыш аяусыз. Ул беркемне дә аяп тормый. Сугыш дигән сүз әйтү белән нәрсә күз алдына килә?( Күз яше, кайгы, бәхетсезлек...). Безнең үзебезнең авылдан да әлеге дәһшәтле сугышта ... артык якташыбыз катнашкан. Шул китүдән аларның яртысыннан азрагы гына туган – үскән җирләренә әйләнеп кайта алды. Хәтер китабы һәм “Алар җиңү белән кайттылар” дигән китап белән дә таныштык. Дошманга күрсәткән батырлыклары өчен җөмһүриятебезнең 200 дән артык кешесе иң югары мактаулы исемгә - Советлар Союзы Герое исеменә лаек булдылар.

**3. Батырлык та күп төрле.**

Ф. Яруллин болай ди: *“Батырлык! Нәрсә соң ул батырлык? Газинурлар, Матросовлар шикелле күкрәгең белән дошман амбразурасын каплаумы, әллә үзең ач чакта соңгы телем икмәгең белән бүлешүме? Кешеләр төрле - төрле булган кебек, батырлык та күп төрле шул”.* (Ф. Яруллин. Җилкәннәр җилдә сынала. Сайланма әсәрләр).

- Ф. Яруллин белән батырлык төшенчәсен бәйләп буламы? Аның тормышы һәм иҗаты турында нәрсәләр беләсез?

- Ф. Яруллин яшәве һәм иҗат итүе үзе бер батырлык. Гарип килеш тә үзендә көч табып, иҗатка тартылып гомер кичерүе, күп кешеләр кабатлый алмый торган батырлык үрнәге. Ә Нурсөя ханымның (хатыны) аны аңлап, яшь сабыйлардай тәрбияләп торуы – тагын бер батырлык.

**4. Төркемнәрдә эшләү.**

**1нче бирем** ***Мәкальләр доньясында.***

- Балалар! Хәзер уен уйнап алыйк! Мәкальләрне мин башлыйм- сез дәвам итәрсез.

1. Батыр яуда ... *беленер.*
2. Батырга таяк та ... *корал.*

3. Батыр башлап җибәрә, артыннан мең кул ... *иярә.*
4. Батыр баткактан ... *курыкмас.*
5. Батыр үз халкын ... *яклый.*
6. Батырлыгыңны мәйданда ... *сынат*
7. Батырлыкта – ... *матурлык.*

**2нче бирем *Бүгенге тыныч шартларда кеше батыр була аламы?***
- Моның өчен нәрсә эшләргә кирәк?
- Кыю, патриот, түзем, тәвәккәл, туры сүзле, ихтыярлы кебек сыйфатларны батырлыкка кертергә буламы? (Укучы җавабы: кешедә бу сыйфатлар булмаса, ул батырлык эшли алмас иде).
- Бу очракта батырлык нәрсәдә күренә? (Батырлыкны бүгенге тыныч шартларда да эшләргә мөмкин. Намус белән яшәгән кешенең гомере үзе бер батырлык. Тырыш хезмәт куеп эшләп, Хезмәт Батыры була ала. Батыр булу өчен, кеше тиешенчә игътибарлы, сизгер, үз – үзен аямый торган булырга тиеш).
- Ничек батыр булырга? (Укучы җавабы).
- Бүгенге көн батырларына син кемнәрне кертер идең? (Конкрет шәхесләр турында). (Сириядә һәлак булган герой- лётчик Пешков шикелле батырлар).

**3нче бирем *Батырлык турында әсәрләр.***
- Укучылар! Әйдәгез тагын бер сорауга җавап биреп китик әле:
- Батырлык турында нинди китаплар укыганыгыз бар?
  - Башлангыч сыйныфта Ф. Кәримнең “Пионерка Гөлчәчәккә хат”.
  - 5 нче сыйныфта *Ф. Кәримнең “Үлем уены”, Ф. Хөснинең “малай белән Солдат*”.
  - 6 нчы сыйныфта *И. Газинең “Йолдызлы малай”, Л. Ихсанованың “Лачын кыз”.*
  - 7 нче сыйныфта Г. Кутуйның *“Сагыну”, Ә. Еникинең “Кем җырлады?”.*
  - 8 нче сыйныфта *И. Газинең “Газинур”, Ш. Рәкыйповның “Чәчәкләр дә сөйли белә”, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Дәүлинең “Яшәү белән үлем арасында”.*
- Сугыш дигән сүзне ишеткәч, күз алдына коточкыч күренешләр килә, дидек, нәрсәләр алар?
- Күз яше, кайгы, бәхетсезлек, ...
- Сугыш сүзенең капма – каршы мәгънәдәге сүзе нинди сүз булыр?
- Тынычлык.
- Тынычлык сүзен ничек аңлатырсыз?
- Яшәү, өмет, шатлык, сәламәтлек...
- Димәк, без нәрсә яклы икән?
- Без бу дөньяга ярату, Җирне матурайту өчен килгән. Без тынычлык яклы. Без сәламәт яшәү яклы. Матур яшәү үзе батырлык.
- Укучылар, Һәйкәлләрдәге, геройлар аллеясындагы чәчәкләр хөрмәт, ихтирам билгесе булып утыралар. Телләре булса, алар һәр үткән кешегә менә шулар турында сөйләрләр иде. Җир йөзендә сугышлар кабатланмасын, яшь егетләрнең гомерләре вакытсыз өзелмәсен, әти - әниләр кайгы яше түкмәсен иде.

**4нче бирем *Танылган шәхесләргә сүз бирик.***
- Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?
  - *Бөек эшләрне кылырга ният итү- каһарманнарга хас сыйфаттыр, сабырлы булу исә хакыйкый (чын) ирләргә хас фазыйләттер* /Локман Хәким/
  - *“Батырлык көндәлек очрап торган авырлыкларга үҗәтләнеп каршы барганда тәрбияләнә.”* / Н.А.Островский/
  - *“Батырлык һәм тәвәккәллек – ул әхлаклылык һәм ихтыяр көче, алар һәр кешегә билгеле бер очракта гына түгел, ә көндәлек тормышта, эштә дә кирәк”.* /В.А.Сухомлинский/
- Батырлык, тәвәккәллек, намуслылык, гаделлек кебек сыйфатлар ялкаулык, тәртипсезлек, таркаулык, ялган белән көндәлек көрәштә дә барлыкка килә.

**5нче бирем Хәдис**

- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хәдисләрен укып, алар турында үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

    - ***Батырлык кешеләрне көрәшеп егуда түгел, бәлки ачу вакытында үзен тота белүдә.***

- Кешенең героик характеры үзендәге начар сыйфатларны җиңүдән башлана.

**5. Батырлыкның төп билгеләре:**

- Без бүгенге дәрестә кешеләргә хас нинди сыйфатка тукталып үттек? (Батырлык, шул сыйфатның эчтәлеген ачтык, асылына төшендек)
- Алда сөйләгәннәрне файдаланып, батырлыкның төп билгеләрен барлап чыгыйк.
    - *Батырлык ул рухи матурлык.*
    - *Ул гадәттән тыш шартларда кешегә үлем куркынычы янаган вакытта эшләнә.*
    - *Батырлар дошманнарга зур зыян китерә: аның техникасы, җанлы көчләрен юк итә.*
    - *Ул, хәрби бурычын үтәү өчен, бөтен көчен, белемен, сәләтен бирә, хәрби техника һәм коралдан оста файдалана.*
    - *Батыр курку хисен җиңә.*
    - *Батыр үз өстенә җаваплылык хисе, бурыч йөкли.*
    - *Батырлык ниндидә хәлиткеч вакытта эшләнә.*
    - *Батырлыкны кеше үз эшенең гадел, изге булуына, хаклыгына ышанганда гына эшли.*
    - *Батырлык һәрвакыт үз-үзеңне корбан итәргә әзер булуны таләп итә.*

- Әнә шуңа күрә дә батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җыр – дастаннарга кергән. Һәм буыннардан – буыннарга күчеп, бүгенге көннәргә килеп җиткән.
- Рәхим итеп. Р. Миңнуллинның “Батыр булыгыз” шигырен тыңлагыз.

Батырлыкны эшли ала
Бөтен кеше дә.
Аның өчен кирәк түгел
Алып көче дә.
Ә моның өчен:
Яратырга кирәк бары
Туган җиреңне,
Әти - әниеңне,
Туган илеңне.

**6. Безнең киңәшләр яки үз- үзеңдә батырлык сыйфатын тәрбияләү план үрнәге-** укучылар белән бергә төзелә**)**

**-** Батырлык эшләү өчен үзеңне ничек чыныктырырга?
- Үзеңдә булган курку хисен җиңергә.
- Үзеңдә җаваплылык хисен тәрбияләргә, сүзеңдә торырга.
- Нәттә эшлисе килмәгән бик кирәкле эшләрне җиренә җиткереп башкарырга.
- Көндәлек тормышта очраган авырлыкларны җиңеп чыгарга.
- Ачу килгән вакытта ачуланмыйча үзеңне кулга алырга.
- Зур максатлар куеп, аларга ирешергә.
- Катлаулы (куркыныч, авыр) ситуацияләр килеп чыкканда, тәвәкәллек кылып, үзеңнең батырлыгыңны сынап карага.

**V. Рефлексия. Йомгаклау.**
– Укучылар, бүгенге дәрес ничек атала? (“Нәрсә ул батырлык?)
- Ә менә сез батырлыкны ничек аңладыгыз? Нәрсә соң ул батырлык?
- Чыннан да, батырлык темасы бүгенге көндә дә актуаль.
- Н.Островский батырлык турында нәрсә дигән? (“*Батырлык көндәлек очрап торган авырлыкларга үҗәтләнеп каршы барганда тәрбияләнә.”*)
- *“Батырлык кешеләрне көрәшеп егуда түгел, бәлки ачу вакытында үзен тота белүдә”* дигән сүзне кем әйткән? Аны ничек аңлыйсыз?
- Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграф итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчанда онытмыйк.
- Тормышта һәрчак батырлыкка урын бар, тик аңа юл үзеңдә бурычлылык хисе, сәяси өлгергәнлек, җаваплылык, әхлакый тотрыклылык тәрбияләү аша үтә.

**VI. Өйгә эш.** Батыр туганнар, авылдашлар турында сөйләргә.